ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $13^{12}$ пункт өстәргә:

«$13^{12}$) Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 8 өлеше нигезендә төзелеш контроле үткәрү турында карар кабул итү;»;

2) 6 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яисә) эшләр башкаручы оешма» сүзләрен «подряд оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында:

беренче абзацта «аңа түбәндәгеләр кушып бирелә» сүзләрен «анда Россия Федерациясе Торак кодексының 46 статьясындагы 1 һәм $1^{1}$ өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органына җибәрү турында белешмәләр чагылдырылырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасында «күчермәсе» сүзен «төп нөсхәсе» сүзләренә алмаштырырга;
«в» һәм «г» пунктчаларын үз көчен югалткан дип танырга;
б) 2 өлешнең 1, 3 һәм 4 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 12 декабрь
№ 96-ТРЗ